**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 27 февралендәге 475 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2018 елның 3 июлендәге 3854 номерлы**
**«Казан шәһәре муниципаль белем бирү оешмалары**
**хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы**
**карарына үзгәреш кертү хакында**

Казан шәһәре муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне җайга сала торган муниципаль норматив хокукый актларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының гамәлдә булган 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карарына (2018 елның 31 октябрендәге 965 номерлы, 2018 елның 29 декабрендәге 1262 номерлы, 2019 елның 6 маендагы 380 номерлы, 2019 елның 11 июлендәге 565 номерлы, 2019 елның 28 августындагы 714 номерлы, 2019 елның 2 ноябрендәге 1008 номерлы, 2019 елның 30 декабрендәге 1278 номерлы, 2020 елның 16 апрелендәге 294 номерлы, 2020 елның 21 маендагы 413 номерлы, 2020 елның 1 сентябрендәге 772 номерлы, 2020 елның 23 октябрендәге 954 номерлы, 2021 елның 26 июлендәге 645 номерлы, 2021 елның 6 сентябрендәге 821 номерлы, 2021 елның 29 октябрендәге 1021 номерлы, 2021 елның 30 октябрендәге 1030 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 566 номерлы, 2022 елның 22 сентябрендәге 1027 номерлы, 2023 елның 11 мартындагы 232 номерлы, 2023 елның 19 августындагы 989 номерлы, 2023 елның 16 октябрендәге 1312 номерлы, 2023 елның 31 октябрендәге 1377 номерлы, 2023 елның 7 ноябрендәге 1431 номерлы, 2024 елның 11 маендагы 318 номерлы, 2024 елның 24 июнендәге 454 номерлы, 2024 елның 25 сентябрендәге 830 номерлы, 2024 елның 14 ноябрендәге 1003 номерлы, 2024 елның 30 декабрендәге 1273 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып) туры китерү максатыннан **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 3 июлендәге 3854 номерлы «Казан шәһәре муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 19 мартындагы 869 номерлы,

2019 елның 29 октябрендәге 3921 номерлы, 2022 елның 28 февралендәге 563 номерлы, 2022 елның 6 апрелендәге 962 номерлы, 2023 елның 18 гыйнварындагы 110, 111 номерлы, 2024 елның 9 февралендәге 453 номерлы, 2024 елның 16 сентябрендәге 3906 номерлы, 2024 елның 22 ноябрендәге 4770 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Казан шәһәренең гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә, 6.2 пуктның 6.2.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә:

«6.2.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр педагогик хезмәткәрләр һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренә аларның гамәлдәге квалификация категориясе булган очракта квалификация категориясенең гамәлдә булу вакыты чикләрендә бирелә.

Квалификация категориясе өчен түләүләр тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән билгеләнә (үзгәртелә).

Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$) башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган педагогик хезмәткәрләр һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk}=O_d\times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган гомуми белем бирү оешмалары мәгариф хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{kk}$ – квалификация категориясе өчен 1 таблицада китерелгән өстәмә түләү күләме.

**1 таблица**

**Башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф хезмәткәрләренә квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләмнәре**

| Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |

| Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|---|
| | | |
| Беренче | Беренче | 10,0 |
| | Югары | 22,0 |
| Икенче | Беренче | 12,0 |
| | Югары | 24,0 |
| Өченче | Беренче | 12,0 |
| | Югары | 24,0 |
| Дүртенче | Беренче | 12,0 |
| | Югары | 24,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Беренче | 12,0 |
| | Югары | 24,0 |
| Икенче | Беренче | 12,0 |
| | Югары | 24,0 |
| Өченче | Беренче | 12,0 |
| | Югары | 24,0 |

Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk(d)}$) гомуми белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган педагогик хезмәткәрләр һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk(d)} = o_d \times \frac{D_{kk(d)}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган гомуми белем бирү оешмалары мәгариф хезмәткәрләренең вазифаи окладлы;

$D_{kk(d)}$ – квалификация категориясе өчен 1.1 таблицада китерелгән өстәмә түләү күләме.

**1.1 таблица**

**Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф хезмәткәрләренә квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләмнәре**

| Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Квалификация категориясе** | **Өстәмә түләүләр күләме, процентларда** |
|---|---|---|
| Беренче | Беренче | 25,0 |
| | Югары | 30,0 |
| Икенче | Беренче | 26,0 |
| | Югары | 31,0 |
| Өченче | Беренче | 27,0 |
| | Югары | 32,0 |
| Дүртенче | Беренче | 28,0 |
| | Югары | 33,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Беренче | 28,0 |
| | Югары | 34,0 |
| Икенче | Беренче | 28,0 |
| | Югары | 34,0 |
| Өченче | Беренче | 28,0 |
| | Югары | 34,0» |

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**